ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

О внесении изменений в статью 10^1 Закона Республики Татарстан «Об обеспечении защиты жилищных прав граждан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 октября 2026 года

Статья 1

Внести в статью 10^1 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 72-ЗРТ «Об обеспечении защиты жилищных прав граждан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2011, № 10 (I часть); 2012, № 11 (I часть); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 27 (часть I), № 94 (часть I); 2018, № 29 (часть I), № 54 (часть I); 2019, № 28 (часть I); 2020, № 37 (часть I); 2021, № 29 (часть I), № 93 (часть I); 2023, № 48 (часть I), № 56 (часть I); 2024, № 16 (часть I) следующие изменения:

1) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Собственнику жилого помещения в многоквартирном доме, указанному в части 1 настоящей статьи (далее для целей настоящей статьи – собственник жилого помещения), взамен освобождаемого им жилого помещения предоставляется возмещение, размер которого определяется в соответствии с частью 7 статьи 32 Жилищного кодекса Российской Федерации не ранее чем за шестьдесят дней до дня направления собственнику жилого помещения проекта договора, предусматривающего переход права собственности на жилое помещение, заключаемого между собственником жилого помещения и лицом, обеспечивающим реализацию решения о комплексном развитии территории жилой застройки, указанным в Градостроительном кодексе Российской Федерации, либо лицом, с которым заключен договор о комплексном развитии территории жилой застройки, в случае, если это предусмотрено таким договором о комплексном развитии территории (далее в целях настоящей статьи соответственно – равноценное

возмещение, договор, предусматривающий переход права собственности на жилое помещение). По заявлению собственника жилого помещения ему предоставляется взамен освобождаемого жилого помещения другое жилое помещение с зачетом его стоимости при определении размера равноценного возмещения за изымаемое жилое помещение.»;

2) часть 8 изложить в следующей редакции:

«8. Предоставление равноценного возмещения или жилого помещения с зачетом его стоимости при определении размера равноценного возмещения за освобождаемое жилое помещение, предоставление равнозначного жилого помещения в соответствии с частью 6 настоящей статьи осуществляются на основании договора, предусматривающего переход права собственности на жилое помещение.».

Статья 2

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

2. Действие положений статьи 10^1 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 72-ЗРТ «Об обеспечении защиты жилищных прав граждан» (в редакции настоящего Закона) распространяется на правоотношения, возникшие до дня вступления в силу настоящего Закона, за исключением случаев, если на день вступления в силу настоящего Закона между собственником жилого помещения в многоквартирном доме, указанным в части 1 статьи 10^1 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 72-ЗРТ «Об обеспечении защиты жилищных прав граждан», и лицом, обеспечивающим реализацию решения о комплексном развитии территории жилой застройки, указанным в Градостроительном кодексе Российской Федерации, либо лицом, с которым заключен договор о комплексном развитии территории жилой застройки, в случае, если это предусмотрено таким договором о комплексном развитии территории, заключен договор, предусматривающий переход права собственности на жилое помещение, или имеется вступившее в законную силу решение суда о понуждении этого собственника жилого помещения к заключению указанного договора, об освобождении жилого помещения и о передаче его в собственность одному из лиц, указанных в части 14 статьи 32^1 Жилищного кодекса Российской Федерации.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
29 октября 2026 года
№ 72-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10^1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 октябрендә
кабул ителде

1 статья

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10^1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән күпфатирлы йорттагы торак урын милекчесенә (алга таба әлеге статьяның максатлары өчен – торак урын милекчесе) ул бушата торган торак урынга алмашка түләү бирелә, аның күләме торак урын милекчесе һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында күрсәтелгән, торак төзелеше территориясен комплексларны үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче зат йә, торак төзелеше территориясен комплексларны үстерү турындагы шартнамәдә каралган очракта, территорияне комплексларны үстерү турындагы мондый шартнамә төзегән зат арасында төзелә торган, торак урынга милек хокукы күчү каралган шартнамә проекты торак урын милекчесенә җибәрелгән көнгә кадәр алтмыш көннән дә иртәрәк булмаган вакытта Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 7 өлеше нигезендә билгеләнә (алга таба әлеге статьяның максатлары өчен тиешенчә – торак бәясенә тиң түләү, торак урынга милек хокукы күчү каралган шартнамә). Торак урын милекчесенең гаризасы буенча аңа бушата торган торак урынга алмашка, тартып алына торган

торак урын өчен торак бәясенә тиң түләү күләмен билгеләгәндә бирелә торган торак урынның бәясен кертеп, башка торак урын бирелә.»;

2) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Торак бәясенә тиң түләү яисә, бушата торган торак урын өчен торак бәясенә тиң түләү күләмен билгеләгәндә бирелә торган торак урынның бәясен кертеп, торак урын бирү, әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә шундый ук торак урын бирү торак урынга милек хокукы күчү каралган шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10^1 статьясы нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, моңа әлеге Закон үз көченә кергән көнгә «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10^1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән күпфатирлы йорттагы торак урын милекчесе һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында күрсәтелгән, торак төзелеше территориясен комплексы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче зат йә, торак төзелеше территориясен комплексы үстерү турындагы шартнамәдә каралган очракта, территорияне комплексы үстерү турындагы мондый шартнамә төзегән зат арасында торак урынга милек хокукы күчү каралган шартнамә төзелгән яисә бу торак урын милекчесен күрсәтелгән шартнамәне төзергә мәҗбүр итү турында, торак урынны бушату турында һәм аны Россия Федерациясе Торак кодексының 32^1 статьясындагы 14 өлешендә күрсәтелгән затларның берсенә милеккә тапшыру турында законлы көченә кергән суд карары булган очраклар керми.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • ТАТАРСТАН • АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 29 октябрь
№ 72-ТРЗ